М.Р.Саттарова

КФУ, Казан

# Религиозный пласт лексики материальной культуры

**Резюме.** Настоящая статья посвящается изучению религиозной лексики татарского языка в контексте материальной культуры. Вопрос рассматривается на материале Толкового словаря татарского языка, также использованы этимологические данные отобранных единиц.

**Ключевые слова**: материальная культура, религиозная лексика, татарский язык

## Матди мәдәният лексикасының дини катламы[1]

Телнең лексик байлыгы халык тарихы, аның рухи һәм матди мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә формалаша һәм үсә. Татар теленең сүзлек составын карасак, көндәлек тормышта кулланыла торган берәмлекләрнең турыдан-туры яисә читләтеп булса да, яшәеш, көндәлек тормыш, гореф-гадәтләр һ.б. белән бәйле этномәдәни үзенчәлекләрне чагылдырганлыгын күрергә мөмкин. Милли үзенчәлекләр белән тыгыз үрелеп барган дини күзаллауларның да лексикада урын алуы табигый хәл. Әлеге яссылыкта караган вакытта, татар теле бик бай һәм кызыклы чыганак булып тора. Ул үзенең борынгы төрки телгә барып тоташа торган тәңречелек элементлары, татар халкының билгеле бер өлешен тәшкил иткән керәшен татарлары көнкүреше, сөйләме, гомумән тормышының барлык катламнарына үтеп кергән христиан дине белән бәйле берәмлекләре, һәм, ниһаять, дөнья тарихында иң яшь саналган Ислам диненә кагылышлы лексик катламнарны үз эченә ала.

Дин, беренче чиратта, кешенең рухи ихтыяҗларын күз алдына тотса да, йола, көндәлек гамәлләрне үтәү, хәтта туклану, киенү кебек гадәти мәнфәгатьләрне канәгатьләндерү өчен генә дә матди гәүдәләнешкә ия булган күпсанлы артефактлар булу мәҗбүри. Тирәлегебезне чолгап алган рухи һәм матди мәдәниятны белдерү өчен кулланылган лексик берәмлекләрне өйрәнү,

[1] Работа поддержана грантом РГНФ, проект № 11-14-16029а/В “Историко-лексикографическое описание лексики материальной культуры татарского языка”

аларны тарихи, генетик, синхрон аспектларда анализлау киң һәм тирән нәтиҗәләр ясарга ярдәм итәчәк.

Әлеге мәкаләдә татар телендә кулланыла торган дини лексиканың Ислам дине белән бәйле булган катламына матди мәдәният күзлегеннән чыгып күзәтү ясау максаты куела. Хәзерге татар телендә кулланылышта булган дини лексиканы барлау тел белеменең актуаль мәсьәләләреннән санала, гамәли һәм теоретик кыйммәткә ия.

Татар әдәби теленең бүгенге торышын дини лексика кулланылышы күзлегеннән бәяләү максатыннан “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә теркәлгән сүзләрне турыдан-туры сайлап алу принцибына нигезләнеп, дин тематикасына караган лексик катламның матди мәдәният өлкәсен яктырткан түбәндәге берәмлекләре тупланды: ахирәт: *ахирәт күлмәге* – беренче кат кәфен (56); *бөркәнчек* – 1) электә хатын-кызлар йөзләрен яшерү өчен кием өстеннән башларына каплап куя торган җиңсез махсус япанча (106); *бөти* – чүпрәккә тегеп яки берәр кечкенә букчага салып, муенга асып йөртә, бәла-казалардан, авырулардан, күз тиюдән саклагыч догалар (107); *бөтилек* – бөти савыты, бик бәләкәй букча (107); *госелханә* – госел коену бүлмәсе, тәһарәт бүлмәсе (131); *гошер* – керемнең, алган файданың, табышның уннан бер өлеше: мулла яки мәчет файдасына җыйнала торган җыем (131); *гыйбадәтханә* – гыйбадәт кылу йорты (чиркәү, мәчет, храм, костел, синагога һ.б.) (134); гүр: *гүр сәдакасы* – Үлгән кешенең гөнаһларын йолдыру өчен, мәет өстендә әйтеп, өчесен уздырганчы бирелә торган аяклы мал (137); *дисбе / тәсбих* – 2) җепкә тезелгән йөз төймәдән гыйбарәт җайланма – аның һәр төймәсен Аллага мактау сүзе әйтеп артка шудыралар һәм шулай итеп зекер итүдә билгеле бер ритмга, тәртипкә ирешәләр; *тәсбих анасы* – тәсбихта һәр 33 төймәдән соң куелып, бер төр тәсбих сүзеннән икенчесенә күчүне белдергән зур төймә (146, 585); *догалык* – 2) догалар язылган кәгазь, дәфтәр, китап яки җыентык (149); *зәкят* – 1) шәригать буенча керемнең ярлыларга һәм мәчет файдасына бирелергә тиешле кырыктан бер (1/40) өлеше (168); *зәм-зәм* – 2) Мәккәдә – кәгъбә янындагы изге чишмәнең хаҗга баручылар дәва итеп инанып эчә һәм алып кайта торган изге

суы (168); *ихрам* – 3) хаҗга баручыларның изге җиргә керер алдыннан өсләренә кия торган япма, тән өреткеч кием (201); *комган* – гадәттә җиз һ.б. төрле калайдан эшләнә торган махсус формадагы, тоткалы һәм борынлы су савыты (элек-электән бирле ритуаль юыну-тәһарәт алу өчен файдаланыла) (271); *корбанлык* – корбанга, корбан итеп суярга дип билгеләнгән (терлек) (280); *Коръән* – мөселманнарның изге китабы (Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә дөрес яшәр өчен үзенең илчесе Мөхәммәт пәйгамбәр аша җибәргән сүзләре, кануны) (283); *кыйбланамә* – компас (304); *Кәгъбә* – Сөгуд Гарәбстанында Мәккә шәһәрендәге мөселманнар изге дип санаган, кара ташы булган мәчет, хаҗга баруның төп максаты (315); *кәфен* – 1) үлгәч кешене төреп күмү өчен ак тукыма (317); *манара* – 2) мәчет түбәсендә яки аның янында түгәрәк, дүрт яки күпкырлы тар конус рәвешендә эшләнгән биек корылма (мәзин шунда менеп азан әйтә) (355); *михраб* – мәчеттә мулла намаз уку өчен эшләнгән махсус урын, түр (368); *мәхәллә* – 1) шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше (377); *мәчет* – мөселманнарның намаз укый, гыйбадәт кыла торган изге йорты (377); *мөнбәр* – 1) мәчет эчендә мулла (имам) хөтбә укый торган баскычлы биек урын (379); *намазлык* – намаз укыганда кулланыла торган махсус пакь җәймә (380); *садака / сәдака* – хәер (457, 496); *пәрәнҗә* – чит ир-ат күзеннән чәч, йөз һәм буй-сынны яшерергә киелә торган һәм йөз каплау өчен махсус ат кылыннан куе итеп ясалган челтәре булган озын, киң халат (437); *тәрәтханә / таһарәтханә* – тәһарәт алу өчен махсус бүлмә яисә бина (585, 588); *фытыр / фытыр сәдакасы* – уразадан соң бирелгән сәдака (628); *фытырлык* – 1. Фытырга бирергә дип әзерләнгән әйбер (628); *хиҗап* – 1) йөзне каплап йөри торган пәрдә, пәрәнҗә (633); *хәер-сәдака* – хәергә бирелгән (алынган) һәртөрле сәдака (637); *чадра* – мөселман хатын-кызлар өйдән чыкканда, йөзләрен ят ирләргә күрсәтмәс өчен, бары күзләрен генә ачык калдырып, баштанаяк ябына торган җиңел япма, бөркәнчек (645); *ябынча* – 1) бөркәнчек; 2) пәрәнҗә (724); *үлемтек* – 1. Мәетне җирләгәндә кулланыла торган кирәк-ярак кәфенлек һ.б., сәдака итеп бирелә торган әйберләр (765); җеназа: *җеназа агачы (кабыгы)* – мәетне күтәреп,

зиратка илтү өчен махсус җайланма (774); *җөббә* – мөселманнарда тукымадан тегелгән ирләр өс киеме (790) [1].

Югарыда санап үтелгән лексик берәмлекләрне берничә тематик төркемчәгә берләштерергә мөмкин. Тематик төркемнәргә бүлү Ислам диненең тулы бер тормыш рәвеше булуы белән бәйле. Югарыда билгеләп үтелгән артефактларны белдергән лексик берәмлекләрне семантик яссылыкта түбәндәге төркемнәргә берләштерергә мөмкин:

а) кием-салым атамалары: *ахирәт күлмәге, бөркәнчек, ихрам, кәфен, пәрәнҗә, хиҗап, чадра, ябынча, үлемтек, җөббә һ.б.;*

ә) яшәү урыны, бина, аның өлешләре атамалары: *госелханә, гыйбадәтханә, Кәгъбә, манара, михраб, мәхәллә, мәчет, мөнбәр, тәрәтханә / тәһарәтханә һ.б.*;

б) матди байлык, акча белән бәйле төшенчәләр: *гошер, гүр сәдакасы, зәкят, садака / сәдака, фытыр / фытыр сәдакасы, фытырлык, хәер-сәдака.һ.б.*;

в) Ислам дине нигезен тәшкил итә торган намаз уку белән бәйле предмет атамалары: *дисбе / тәсбих, тәсбих анасы, комган, Коръән, кыйбланамә, намазлык һ.б.;*

г) башка ритуаллар һәм ышанулар белән бәйле әйберләрнең атамалары: *бөти, бөтилек, догалык, зәм-зәм, корбанлык, җеназа агачы (кабыгы) һ.б.*

Семантик аспектта анализланган дүрт дистәгә якын лексик берәмлек татар халкы көнкүрешендә актив кулланыла торган дини лексиканың бары Ислам диненә караганын һәм матди катламын гына белдерә. Шул ук вакытта сүзлектә барлык берәмлекләрнең дә теркәлмәгәнлеген истә тоту мөһим. Генетик яктан сүзләрнең күпчелеге гарәп-фарсы алынмалары булуы табигый. Ислам дине ритуаллары, бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре белән татар халкы тормышына читтән кабул ителгән. Шул сәбәплеме, аерым предметлар сирәк кулланылышка ия. Мәсәлән, пәрәнҗә, чадра, хиҗаб, җөббә кебек киемнәр татар халкында популяр түгел. Әмма Ислам диненең нигезен тәшкил иткән намаз,

хаҗ кебек гамәлләрне, мәетләрне тиешле таләпләргә туры китереп соңгы юлга озату йолаларын үтәүдә кулланыла торган предмет атамалары күпләргә таныш.

Нәтиҗә ясап әйтәндә, бүгенге әдәби телебездә кулланылган дини лексика белдергән төшенчәләр, артефактлар татар халкы тормышының аерылгысыз өлешен тәшкил итә һәм тәрбия, көндәлек тормыш, гореф-гадәтләрне гамәлгә ашыруда актив кулланылалар. Анализланган сүзләр Ислам динен кабул итүгә бәйле рәвештә татар халкының сөйләм теле баюын раслый. Алар халыкның тормыш рәвешенә, дөньяга каршына, бай милли үзенчәлекләренә дини колорит өстәгән.

**Чыганак**

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш.ред.: Ф.А.Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.